Республика Татарстан

Исполнительный
комитет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск
муниципаль районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28.01.2025_________ Менделеевск ш. №56

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юллау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 555 номерлы карары белән расланган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 3.3.3.2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган

федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә».

1.2. Административ регламентның 3.4.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедуралар, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда, шул исәптән гаризаны Регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәү вакытыннан алып башкарыла.

Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән һәм пространство күрсәткечләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә».

1.3. Административ регламентның 3.5.2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү максатларында («Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш) яисә бакча йортын төзүче кәгазьдә төзелешкә рөхсәт бирергә вәкаләтле җирле үзидарә органына шәхси мөрәҗәгать аша тапшыра, шул исәптән күпфункцияле үзәк аша, йә күрсәтелгән органга тапшыру турында хәбәрнамә белән почта юлламасы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы ярдәмендә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла торган хәбәрнамә (алга таба шулай ук – планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә) җибәрә, ул түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

1) төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (физик зат өчен);
2) төзүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булса, моңа керми;
3) (җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), җир кишәрлегенең урнашу урыны адресы һәм тасвирламасы)
4) төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның хокуклары булу турында белешмәләр (мондый затлар булганда);
5) җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (капиталь төзелеш яисә бакча йорты объектыннан) рөхсәт ителгән файдалану рәвеше турында белешмәләр;
6) төзү яисә реконструкцияләү максатларында планлаштырылган төзелеш турында хәбәр бирелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырылган параметрлары турында, шул исәптән җир кишәрлеге чикләреннән чигенүләр турында белешмәләр;
7) шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының мөстәкыйль

кучемсез милек объектларына булу өчен билгеләнмәве турында белешмәләр;
8) почта адресы һәм (яисә) йорт салучы белән элемтә өчен электрон почта адресы);
9) төзүчегә әлеге статьяның 7 өлешендәге 2 пунктында һәм 8 өлешендәге 3 пунктында каралган хәбәрнамәләрне җибәрү ысулы. РФ Шәһәр төзелеше кодексы"ның 51_1 статьясы

1.4. Административ регламентның 3.5.4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү. техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автоматлаштырылган режимда гамәлгә ашырыла.

Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны башкару кысаларында. шул исәптән пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле рәвештә, пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә ".

1.5. Административ регламентның 3.6.1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи затның муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ алуы административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи затның төзелеш, архитектура һәм торак - коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече (алга таба-документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) административ процедураны башкаруга нигез булып тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат: дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару барышында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәтне электрон хезмәттәшлек ярдәмендә күрсәтү һәм муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәктә күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге турында Республика порталы аша хәбәр итә.

Процедураларны техник мөмкинлек булганда үтәү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән мәгълүмат системасын кулланып автоматлаштырылган режимда башкарыла.

Пространство мәгълүматларыннан файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүне кире кагуны) раслый торган документ имзаланган көнне Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты (Башкарма комитет) тарафыннан башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында белешмәләрне мәгълүмат системаларында урнаштыру, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында

хәбәр итү.

2.Район Советының мәгълүмати технологияләре белән тәэмин итү бүлегенә әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәмwww.mendeleevsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Искәндәров

Килештерелде:

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева